ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1238 2016 елның 1 августы

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 июлендә кабул ителгән 924 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 110 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 29 апрелендәге под-832/16 номерлы боерыгы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 июлендә кабул ителгән 924 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең «Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге» 2.6. пунктындагы 2 баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала туу турында таныклык;

ташламаларны раслаучы документлар:

күпбалалы гаилә балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар балалары;

инвалид балалар;

бер әти-әнисе генә булса да инвалид булган гаиләләр.

1.2. 2.15 Пункт. 2 багана 2 бүлекнең «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәткечләре» 2.15. пунктындагы 2 баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- урынның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;

- кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;

- мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

- законда каралган инвалидлар өчен уңайлы шартлар булу.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты характерлана:

- документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

- муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан башкарылган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга карата прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булуы».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
җитәкче урынбасары Л.Р. Юнысов